ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ул. Гагарина, д.13, г. Агрыз, 422230

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Гагарин ур.,13, Әгерҗе шәһәре, 422230

Тел.: (85551) 2-22-46; Факс: 2-22-46; E-mail: isp.agryz@tatar.ru; www. agryz.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«05» апрель 2022 ел № 83

«Әгерҗе үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең яңа штат расписаниесен раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 10 февралендәге 36 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Иж-Бәйки авыл клубын ябу һәм штат берәмлеген "Әгерҗе үзәкләштерелгән клуб системасы" бюджет мәдәният учреждениесенең башка структур бүлекчәсенә тапшыру уңаеннан, эш нәтиҗәлелеген арттыру һәм вазыйфаларны рациональ бүлү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясына, Россия Федерациясе Дәүләт стандартының 1994 елның 26 декабрендәге 367 номерлы карары белән кабул ителгән ОК 016-94 (ОКПДТР) эшче һөнәрләре, хезмәткәр вазыйфалары һәм тариф разрядлары гомумроссия классификаторына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. «Әгерҗе үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең яңа штат расписаниесен раслау турында» Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы башкарма комитетының 2020 елның 10 февралендәге 36 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«Әгерҗе үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесенең штат расписаниесендә:

1) СДК, СК структур бүлекчәсендә:

- «0,25» штат берәмлекләре санында «Мөдир» вазыйфасын төшереп калдырырга (23 нче номерлы Иж-Бәйки авыл клубы секторы);

- 23 нче номерлы Иж-Бәйки авыл клубы секторын төшереп калдырырга.

2) РДК (район мәдәният йорты) структур бүлекчәсендә:

- «0,25» штат берәмлекләре санында «Түгәрәк җитәкчесе» вазыйфасын төшереп калдырырга;

- «Инструктор-массовик» вазыйфасын «Культорганизатор» вазыйфасына үзгәртергә.

3) СДК, СК структур бүлекчәсендә:

- «0,5» штат берәмлекләре санында «Аккомпаниатор» вазыйфасын кертергә (22 нче номерлы Варклед-Бодья авыл клубы секторы).

4) ХЭСның (хуҗалык-эксплуатация хезмәте) структур бүлекчәсендә:

- «0,5» штат берәмлекләре санында «Электр җиһазларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү буенча электромонтер» вазыйфасын төшереп калдырырга;

- «0,5» штат берәмлекләре санында «Җитештерү һәм хезмәт биналарын җыештыручы» вазыйфасын кертергә.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 01 апреленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Әгерҗе үзәкләштерелгән клуб системасы» муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе җитәкчесенә әлеге карар буенча оештыру-штат чараларын үткәрүне тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының рәсми сайтында (https://agryz.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкчесе** **А.Э. Акбашев**